СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Агрыз № 33-9

**«Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 14.11.2012 елның 19-5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (21.03.2023 елның 27-9 номерлы карары редакциясендә)**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, «Хезмәткәрләрне хезмәт командировкаларына җибәрү үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 13 октябрендәге 749 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 14.11.2012 елның 19-5 номерлы карарына кушымтадагы үзгәрешләрне расларга (21.03.2023 елның 27-9 номерлы карар редакциясендә).
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Финанс-бюджет палатасына әлеге карар буенча чыгымнарны финанслауны күздә тотарга.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Советының
14.12.2023 елның 33-9 номерлы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 14.11.2012 елның 19-5 номерлы карарына үзгәрешләр (21.03.2023 елның 27-9 номерлы карар редакциясендә)

1) Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы «а» пунктчасында (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 14.11.2012 елның 19-5 номерлы карарына 1 нче кушымта):

"җитәкчеләр категориясендәге муниципаль хезмәтнең югары вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә ике бүлмәле номерның бәясеннән 5000 (биш мең) сумнан артык түгел» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы территориясендә, ә Татарстан Республикасы территориясеннән читтә 15 000 (унбиш мең) сумга кадәр» сүзтезмәсе өстәргә.